**УКАЗ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
**УКАЗЫ**

**Об образовании Республиканского организационного комитета по проведению в 2026 году Года единства народов России в Республике Татарстан**

В соответствии с Указом Президента Российской Федерации от 25 декабря 2025 года № 962 «О проведении в Российской Федерации Года единства народов России», в целях проведения в 2026 году Года единства народов России в Республике Татарстан **постановляю:**

1. Образовать Республиканский организационный комитет по проведению в 2026 году Года единства народов России в Республике Татарстан.

2. Утвердить Положение о Республиканском организационном комитете по проведению в 2026 году Года единства народов России в Республике Татарстан (приложение № 1) и его состав (приложение № 2).

3. Кабинету Министров Республики Татарстан разработать с учетом предложений Республиканского организационного комитета по проведению в 2026 году Года единства народов России в Республике Татарстан и утвердить республиканский план основных мероприятий по проведению в 2026 году Года единства народов России в Республике Татарстан.

4. Республиканскому агентству по печати и массовым коммуникациям «Татмедиа» обеспечить широкое освещение проведения в 2026 году Года единства народов России в Республике Татарстан.

5. Настоящий Указ вступает в силу со дня его подписания.

**Раис**
**Республики Татарстан** **Р.Н. Минниханов**

АДМИНИСТРАЦИЯ РАИСА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казань, Кремль
13 марта 2026 года
№ 197

Приложение № 1
к Указу Раиса
Республики Татарстан

от «13» марта 2026 года
№ 197

# ПОЛОЖЕНИЕ
## о Республиканском организационном комитете по проведению в 2026 году Года единства народов России в Республике Татарстан

1. Республиканский организационный комитет по проведению в 2026 году Года единства народов России в Республике Татарстан (далее – Организационный комитет) является коллегиальным органом, образованным в целях проведения в Республике Татарстан мероприятий в рамках Года единства народов России, а также обеспечения координации деятельности органов государственной власти Республики Татарстан, территориальных органов федеральных органов исполнительной власти по Республике Татарстан, органов местного самоуправления муниципальных образований Республики Татарстан (далее – органы местного самоуправления), организаций и общественных объединений, участвующих в реализации вышеуказанных мероприятий.

2. Организационный комитет в своей деятельности руководствуется Конституцией Российской Федерации, федеральными конституционными законами, федеральными законами, иными нормативными правовыми актами Российской Федерации, Конституцией Республики Татарстан, законами Республики Татарстан, иными нормативными правовыми актами Республики Татарстан, а также настоящим Положением.

3. Основными задачами Организационного комитета являются:

а) разработка предложений в республиканский план основных мероприятий по проведению в 2026 году Года единства народов России в Республике Татарстан (далее – План мероприятий);

б) обеспечение координации деятельности органов государственной власти Республики Татарстан, территориальных органов федеральных органов исполнительной власти по Республике Татарстан, органов местного самоуправления, организаций и общественных объединений по решению задач, связанных с исполнением Плана мероприятий;

в) рассмотрение вопросов исполнения Плана мероприятий и разработка предложений по его корректировке.

4. Организационный комитет в целях реализации стоящих перед ним задач имеет право:

а) запрашивать и получать в соответствии с законодательством от органов государственной власти Республики Татарстан, территориальных органов федеральных органов исполнительной власти по Республике Татарстан, органов местного самоуправления, организаций и общественных объединений информационные материалы по вопросам, относящимся к компетенции Организационного комитета;

б) создавать в установленном порядке временные рабочие группы для решения вопросов, относящихся к компетенции Организационного комитета;

в) приглашать на свои заседания представителей органов государственной власти Республики Татарстан, территориальных органов федеральных органов исполнительной власти по Республике Татарстан, органов местного самоуправления, организаций и общественных объединений.

5. Состав Организационного комитета утверждается Раисом Республики Татарстан.

6. В состав Организационного комитета входят председатель, заместители председателя, секретарь и иные члены Организационного комитета, которые принимают участие в его работе на общественных началах.

7. Председатель Организационного комитета:

а) руководит работой Организационного комитета, определяет перечень, сроки и порядок рассмотрения вопросов на заседаниях Организационного комитета;

б) распределяет полномочия (обязанности) между заместителями председателя и членами Организационного комитета;

в) определяет и утверждает повестку дня, дату, время и место проведения заседаний;

г) назначает на время своего отсутствия одного из заместителей председателя Организационного комитета исполняющим обязанности председателя Организационного комитета;

д) подписывает протоколы заседаний и другие документы Организационного комитета.

8. Секретарь Организационного комитета:

а) принимает участие в заседаниях Организационного комитета;

б) уведомляет членов Организационного комитета о месте, дате и времени проведения заседания, рассылает повестку дня заседания не менее чем за пять дней до дня проведения заседания;

в) отвечает за подготовку протоколов заседаний и других документов Организационного комитета.

9. Члены Организационного комитета:

а) участвуют лично в заседаниях Организационного комитета;

б) выносят на обсуждение предложения по вопросам, находящимся в компетенции Организационного комитета;

в) осуществляют иные мероприятия по подготовке, исполнению решений Организационного комитета.

10. Заседания Организационного комитета проводятся по мере необходимости.

11. Заседание Организационного комитета считается правомочным, если в нем принимают участие более половины его членов.

12. Решения Организационного комитета принимаются большинством голосов присутствующих на заседании членов Организационного комитета. При равенстве голосов голос председательствующего на заседании Организационного комитета является решающим. В случае отсутствия члена Организационного комитета на заседании он вправе изложить в письменной форме свое мнение по рассматриваемым вопросам, которое подлежит обязательному приобщению к протоколу заседания Организационного комитета.

13. По результатам рассмотрения вопросов на заседании Организационного комитета принимаются решения, которые оформляются протоколом. Протокол заседания Организационного комитета подписывается председательствующим.

14. Решения, принимаемые Организационным комитетом, доводятся до заинтересованных органов государственной власти Республики Татарстан, территориальных органов федеральных органов исполнительной власти по Республике Татарстан, органов местного самоуправления, организаций, общественных объединений и иных заинтересованных лиц для руководства при осуществлении текущей деятельности.

15. На основании решений Организационного комитета могут разрабатываться проекты актов Раиса Республики Татарстан и Кабинета Министров Республики Татарстан.

16. Материально-техническое, документационное и информационное обеспечение деятельности Организационного комитета осуществляется Аппаратом Кабинета Министров Республики Татарстан.

Приложение № 2
к Указу Раиса
Республики Татарстан
от «13» марта 2026 года
№ 197

# СОСТАВ
## Республиканского организационного комитета по проведению в 2026 году Года единства народов России в Республике Татарстан

| | |
|---|---|
| Мухаметшин Фарид Хайруллович | Председатель Государственного Совета Республики Татарстан, председатель региональной общественной организации «Ассамблея представителей народов, проживающих на территории Республики Татарстан», председатель Организационного комитета (по согласованию) |
| Ахметов Марат Готович | заместитель Председателя Государственного Совета Республики Татарстан, заместитель председателя Организационного комитета (по согласованию) |
| Терентьев Александр Михайлович | председатель Общественной палаты Республики Татарстан, заместитель председателя Организационного комитета (по согласованию) |
| Шайхразиев Василь Габтелгаязович | заместитель Премьер-министра Республики Татарстан, заместитель председателя Организационного комитета |
| Низамова Ляйсан Гаптелхановна | начальник Управления культуры и развития языков народов Республики Татарстан Аппарата Кабинета Министров Республики Татарстан, секретарь Организационного комитета |

| | |
|---|---|
| Александровская Ирина Алексеевна | председатель правления региональной общественной организации «Русское национально-культурное объединение Республики Татарстан», заместитель председателя региональной общественной организации «Ассамблея представителей народов, проживающих на территории Республики Татарстан» (по согласованию) |
| Арзамазов Алексей Андреевич | председатель региональной общественной организации «Национально-культурная автономия удмуртов Республики Татарстан» (по согласованию) |
| Ахмадиева Роза Шайхайдаровна | ректор федерального государственного бюджетного образовательного учреждения высшего образования «Казанский государственный институт культуры» (по согласованию) |
| Аюпова Ирада Хафизяновна | министр культуры Республики Татарстан |
| Бикчантаев Фарид Рафкатович | председатель регионального отделения Общероссийской общественной организации «Союз театральных деятелей Российской Федерации (Всероссийское театральное общество)» – «Союз театральных деятелей Республики Татарстан» (по согласованию) |
| Валиуллин Ренат Накифович | заместитель председателя региональной общественной организации «Ассамблея представителей народов, проживающих на территории Республики Татарстан» – руководитель Исполнительного комитета Совета региональной общественной организации «Ассамблея представителей народов, проживающих на территории Республики Татарстан», депутат Государственного Совета Республики Татарстан (по согласованию) |

| | |
|---|---|
| Габдрахманова Гульнара Закариевна | председатель Государственного комитета Республики Татарстан по архивному делу |
| Гильмутдинова Ольга Александровна | директор государственного автономного профессионального образовательного учреждения «Казанское художественное училище имени Н.И. Фешина» (техникум) (по согласованию) |
| Губайдуллин Экзам Саматович | председатель Ассоциации «Совет муниципальных образований Республики Татарстан» (по согласованию) |
| Гущин Иван Николаевич | председатель Комитета Республики Татарстан по охране объектов культурного наследия |
| Зайдуллин Ркаил Рафаилович | председатель региональной общественной организации «Союз писателей Республики Татарстан» Общероссийской общественной организации «Союз писателей России», депутат Государственного Совета Республики Татарстан (по согласованию) |
| Залялова Анфиса Григорьевна | директор государственного автономного профессионального образовательного учреждения «Казанский педагогический колледж» (по согласованию) |
| Зарипов Айрат Ринатович | председатель Комитета Государственного Совета Республики Татарстан по образованию, культуре, науке и национальным вопросам (по согласованию) |
| Зарипова Эльмира Амировна | министр труда, занятости и социальной защиты Республики Татарстан |
| Кадыров Азат Рифгатович | министр по делам молодежи Республики Татарстан |
| Кадыров Тимур Рафкатович | директор государственного бюджетного учреждения «Дом Дружбы народов Татарстана» (по согласованию) |

| | |
|---|---|
| Камалов Ильяс Файзрахманович | председатель региональной общественной организации «Союз композиторов Республики Татарстан» (по согласованию) |
| Кукушкина Наталья Владимировна | председатель Совета региональной общественной организации «Национально-культурная автономия марийцев Республики Татарстан» (по согласованию) |
| Леонов Владимир Александрович | министр спорта Республики Татарстан |
| Метшин Ильсур Раисович | глава муниципального образования города Казани (по согласованию) |
| Минниханов Рифкат Нургалиевич | президент государственного научного бюджетного учреждения «Академия наук Республики Татарстан» (по согласованию) |
| Мухарлямов Руслан Робертович | заместитель Руководителя Администрации Раиса Республики Татарстан – руководитель Департамента Раиса Республики Татарстан по вопросам внутренней политики |
| Сабитова Наталья Михайловна | председатель региональной общественной организации «Национально-культурная автономия мордвы Республики Татарстан», заместитель председателя региональной общественной организации «Ассамблея представителей народов, проживающих на территории Республики Татарстан» (по согласованию) |
| Салимгараев Айдар Саитгараевич | руководитель Республиканского агентства по печати и массовым коммуникациям «Татмедиа» |
| Саляхов Рабис Магалимович | председатель «Союз художников Татарстана» регионального отделения Всероссийской творческой общественной организации «Союз художников России» (по согласованию) |

| | |
|---|---|
| Самаренкин Дмитрий Анатольевич | председатель Совета региональной общественной организации «Чувашская национально-культурная автономия в Республике Татарстан», заместитель председателя региональной общественной организации «Ассамблея представителей народов, проживающих на территории Республики Татарстан», депутат Государственного Совета Республики Татарстан (по согласованию) |
| Саубанова Раушания Киямутдиновна | директор государственного автономного профессионального образовательного учреждения «Казанский техникум народных художественных промыслов» (по согласованию) |
| Сафин Ленар Ринатович | ректор федерального государственного автономного образовательного учреждения высшего образования «Казанский (Приволжский) федеральный университет» (по согласованию) |
| Сулейманов Тимур Джавдетович | председатель Совета регионального отделения Общероссийского общественно-государственного движения детей и молодежи «Движение первых» Республики Татарстан (по согласованию) |
| Сусаев Селим Сайпович | председатель региональной общественной организации Республики Татарстан «Чеченское национально-культурное объединение «Вайнах» (Наш народ), заместитель председателя региональной общественной организации «Ассамблея представителей народов, проживающих на территории Республики Татарстан» (по согласованию) |
| Хадиуллин Ильсур Гараевич | министр образования и науки Республики Татарстан |
| Хасанов Гали Ахтарович | председатель региональной общественной организации «Национально-культурная автономия башкир – Курултай (конгресс) башкир Республики Татарстан» (по согласованию) |

| | |
|---|---|
| Ягафаров Ильдар Рашитович | председатель правления регионального отделения Общероссийской общественной организации «Союз кинематографистов Российской Федерации» Республики Татарстан (по согласованию) |

---

**УКАЗ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
**УКАЗЫ**

**2026 елда Татарстан Республикасында Россия халыклары бердәмлеге елын уздыру буенча республика оештыру комитеты төзү турында**

Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясендә Россия халыклары бердәмлеге елын үткәрү турында» 2025 елның 25 декабрендәге 962 номерлы Указы нигезендә, Татарстан Республикасында 2026 елда Россия халыклары бердәмлеге елын уздыру максатларында **карар бирәм**:

1. 2026 елда Татарстан Республикасында Россия халыклары бердәмлеге елын уздыру буенча республика оештыру комитеты төзергә.

2. 2026 елда Татарстан Республикасында Россия халыклары бердәмлеге елын уздыру буенча республика оештыру комитеты турында нигезләмәне (1 нче кушымта) һәм аның составын (2 нче кушымта) расларга.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына Татарстан Республикасында Россия халыклары бердәмлеге елын уздыру буенча республика оештыру комитетының тәкъдимнәрен исәпкә алып, Татарстан Республикасында Россия халыклары бердәмлеге елын уздыру буенча республикадагы төп чаралар планын эшләргә һәм расларга.

4. Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына Татарстан Республикасында Россия халыклары бердәмлеге елын уздыруны массакүләм мәгълүмат чараларында киң яктыртуны тәэмин итәргә.

5. Әлеге Указ аңа кул куелган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Рәисе** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2026 ел, 13 март
№ 197

Татарстан Республикасы
Рәисенең
2026 елның «13» мартындагы
197 номерлы Указына
1 нче кушымта

**2026 елда Татарстан Республикасында Россия халыклары бердәмлеге елын уздыру буенча республика оештыру комитеты турында**
**НИГЕЗЛӘМӘ**

1. 2026 елда Татарстан Республикасында Россия халыклары бердәмлеге елын уздыру буенча республика оештыру комитеты (алга таба – Оештыру комитеты) Россия халыклары бердәмлеге елы кысаларында 2026 елда Татарстан Республикасында чаралар уздыру, шулай ук әлеге чараларны уздыруда катнаша торган Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнары, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре җирле үзидарә органнары (алга таба – җирле үзидарә органнары), оешмалар һәм иҗтимагый берләшмәләр эшчәнлеген координацияләүне тәэмин итү максатларында төзелгән коллегиаль орган булып тора.

2. Оештыру комитеты Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль конституциячел законнарга, федераль законнарга, Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларына, Татарстан Республикасы Конституциясенә, Татарстан Республикасы законнарына, Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актларына, шулай ук әлеге Нигезләмәгә таянып эшчәнлек алып бара.

3. Оештыру комитетының төп бурычлары түбәндәгеләр:

а) 2026 елда Татарстан Республикасында Россия халыклары бердәмлеге елын уздыру буенча республикадагы төп чаралар планына (алга таба – Чаралар планы) кертү өчен тәкъдимнәр әзерләү;

б) Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнары, җирле үзидарә органнары, оешмалар һәм иҗтимагый берләшмәләрнең Чаралар планын үтәүгә бәйле бурычларны хәл итү буенча эшчәнлеген координацияләүне тәэмин итү;

в) Чаралар планын үтәү буенча тәкъдимнәр эшләү мәсьәләләрен карап тикшерү һәм аңа үзгәрешләр кертү.

4. Үз алдында торган бурычларны үтәү максатында Оештыру комитеты түбәндәгеләргә хокуклы:

а) Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарыннан, федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, оешмалар һәм иҗтимагый берләшмәләрдән законнар нигезендә Оештыру комитеты компетенциясенә кергән мәсьәләләр буенча мәгълүмати материаллар соратып алырга;

б) Оештыру комитеты компетенциясенә кергән мәсьәләләрне хәл итү өчен билгеләнгән тәртиптә вакытлы эш төркемнәре оештырырга;

в) үз утырышларына Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнары, җирле үзидарә органнары, оешмалар һәм иҗтимагый берләшмәләр җитәкчеләрен чакырырга.

5. Оештыру комитетының составы Татарстан Республикасы Рәисе тарафыннан раслана.

6. Оештыру комитеты составына Оештыру комитеты рәисе, Оештыру комитеты рәисе урынбасарлары, секретарь һәм Оештыру комитеты әгъзалары керә, алар Оештыру комитеты эшендә җәмәгать башлангычларында катнаша.

7. Оештыру комитеты рәисе:

а) Оештыру комитеты эшенә җитәкчелек итә, Оештыру комитеты утырышларында карала торган мәсьәләләр исемлеген, аларны карап тикшерү срокларын һәм тәртибен билгели;

б) Оештыру комитеты рәисе урынбасарлары һәм әгъзалары арасында вәкаләтләрне (вазыйфаларны) бүлә;

в) утырышларның көн тәртибен, уздыру датасын, вакытын һәм урынын билгели һәм раслый;

г) үзе эш урынында булмаган очракта, Оештыру комитеты рәисе урынбасарларының берсен Оештыру комитеты рәисе вазыйфаларын башкаручы итеп билгели;

д) Оештыру комитеты утырышлары беркетмәләренә һәм башка документларга кул куя.

8. Оештыру комитеты секретаре:

а) Оештыру комитеты утырышларында катнаша;

б) Оештыру комитеты утырышын уздыру көненә кадәр кимендә биш эш көне кала, Оештыру комитеты әгъзаларына утырыш уздыру урыны, датасы һәм вакыты турында хәбәр итә, утырышның көн тәртибен юллый;

в) Оештыру комитеты утырышлары беркетмәләрен һәм башка документларын әзерләү өчен җаваплы була.

9. Оештыру комитеты әгъзалары:

а) Оештыру комитеты утырышларында шәхсән катнашалар;

б) Оештыру комитеты компетенциясенә керә торган мәсьәләләр буенча фикер алышуга тәкъдимнәр бирәләр;

в) Оештыру комитеты карарларын әзерләү, үтәү буенча кирәкле башка чараларны башкара.

10. Оештыру комитеты утырышлары кирәк булган саен, ләкин кимендә ярты елга бер тапкыр үткәрелә.

11. Оештыру комитеты утырышы, анда әгъзаларының яртысыннан күбрәге катнашкан очракта, гамәлгә хокуклы дип санала.

12. Оештыру комитеты карарлары утырышта катнашкан Оештыру комитеты әгъзаларының күпчелек тавышы белән кабул ителә. Тавышлар саны бертигез булганда, Оештыру комитеты утырышында рәислек итүченең тавышы хәлиткеч булып санала. Утырышта катнашмаган очракта, Оештыру комитеты әгъзасы карап тикшерелә торган мәсьәләләр буенча үз фикерен язма рәвештә белдерергә хокуклы. Ул мәҗбүри рәвештә Оештыру комитеты утырышы беркетмәсенә теркәлергә тиеш.

13. Оештыру комитеты утырышында мәсьәләләрне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча карарлар кабул ителә, алар беркетмә рәвешендә рәсмиләштерелә. Оештыру комитеты утырышының беркетмәсенә утырышта рәислек итүче кул куя.

14. Оештыру комитеты тарафыннан кабул ителгән карарлар Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең кызыксынган органнарына, федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнарына, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре җирле үзидарә органнарына, оешмаларга һәм иҗтимагый берләшмәләргә, кызыксынган башка затларга эшчәнлек алып барганда куллану өчен җиткерелә.

15. Оештыру комитеты карарлары нигезендә Татарстан Республикасы Рәисе һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты актлары проектлары әзерләнергә мөмкин.

16. Оештыру комитеты эшчәнлеген матди-техник яктан, документлар һәм мәгълүмат белән тәэмин итүне Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты башкара.

___________

Татарстан Республикасы
Рәисенең
2026 елның «13» мартындагы
197 номерлы Указына
2 нче кушымта

**2026 елда Татарстан Республикасында Россия халыклары бердәмлеге елын уздыру буенча республика оештыру комитеты**
**СОСТАВЫ**

| | |
|---|---|
| Мөхәммәтшин Фәрит Хәйрулла улы | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе, «Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче халыклар вәкилләре ассамблеясе» төбәк иҗтимагый оешмасы рәисе, Оештыру комитеты рәисе (килешү буенча) |
| Әхмәтов Марат Готыф улы | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе урынбасары, Оештыру комитеты рәисе урынбасары (килешү буенча) |
| Терентьев Александр Михайлович | Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы рәисе (килешү буенча), Оештыру комитеты рәисе урынбасары (килешү буенча) |
| Шәйхразыев Васил Габделгаяз улы | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары, Оештыру комитеты рәисе урынбасары |
| Низамова Ләйсән Габделхан кызы | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Мәдәният һәм Татарстан Республикасы халыклары телләрен үстерү идарәсе башлыгы, Оештыру комитеты секретаре |

| | |
|---|---|
| Александровская Ирина Алексеевна | «Татарстан Республикасының рус милли-мәдәни берләшмәсе» төбәк иҗтимагый оешмасы идарәсе рәисе, «Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче халыклар вәкилләре ассамблеясе» төбәк иҗтимагый оешмасы рәисе урынбасары (килешү буенча) |
| Арзамазов Алексей Андреевич | «Татарстан Республикасының удмурт милли-мәдәни мохтарияте» төбәк иҗтимагый оешмасы рәисе (килешү буенча) |
| Әхмәдиева Роза Шәйхәйдәр кызы | «Казан дәүләт мәдәният институты» федераль дәүләт бюджет югары белем бирү мәгариф учреждениесе ректоры (килешү буенча) |
| Әюпова Ирада Хафизҗан кызы | Татарстан Республикасы мәдәният министры |
| Бикчәнтәев Фәрит Рәфкать улы | «Россия Федерациясе Театр әһелләре берлеге (Бөтенроссия театр җәмгыяте)» гомумроссия иҗтимагый оешмасы төбәк бүлекчәсе – «Татарстан Республикасы Театр әһелләре берлеге» рәисе (килешү буенча) |
| Вәлиуллин Ренат Нәкыйф улы | «Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче халыклар вәкилләре ассамблеясе» төбәк иҗтимагый оешмасы рәисе урынбасары – «Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче халыклар вәкилләре ассамблеясе» төбәк иҗтимагый оешмасы Советы Башкарма комитеты җитәкчесе, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты (килешү буенча) |
| Габдрахманова Гөлнара Зәкәрия кызы | Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты рәисе |

| | |
|---|---|
| Гыйльметдинова<br>Ольга Александровна | «Н.И. Фешин исемендәге Казан сәнгать училищесы» (техникумы) дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе директоры (килешү буенча) |
| Гобәйдуллин<br>Әгъзам Самат улы | «Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре советы» ассоциациясе рәисе (килешү буенча) |
| Гущин<br>Иван Николаевич | Татарстан Республикасының Мәдәни мирас объектларын саклау комитеты рәисе |
| Зәйдуллин<br>Ркаил Рафаил улы | «Россия Язучылар берлеге» гомумроссия җәмәгать оешмасының «Татарстан Республикасы Язучылар берлеге» төбәк җәмәгать оешмасы рәисе, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты (килешү буенча) |
| Җәләлова<br>Анфиса Григорьевна | «Казан педагогика көллияте» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе директоры (килешү буенча) |
| Зарипов<br>Айрат Ринат улы | Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе (килешү буенча) |
| Зарипова<br>Эльмира Әмир кызы | Татарстан Республикасы хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министры |
| Кадыйров<br>Азат Рифгать улы | Татарстан Республикасы яшьләр эшләре министры |
| Кадыйров<br>Тимур Рәфкать улы | «Татарстанның Халыклар дуслыгы йорты» дәүләт бюджет учреждениесе директоры (килешү буенча) |

| | |
|---|---|
| Камалов<br>Ильяс Фәйзрахман улы | «Татарстан Республикасы Композиторлар берлеге» төбәк иҗтимагый оешмасы рәисе (килешү буенча) |
| Кукушкина<br>Наталья Владимировна | «Татарстан Республикасының мари милли-мәдәни мохтарияте» төбәк иҗтимагый оешмасы советы рәисе (килешү буенча) |
| Леонов<br>Владимир Александрович | Татарстан Республикасы спорт министры |
| Метшин<br>Илсур Рәис улы | Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башлыгы (килешү буенча) |
| Миңнеханов<br>Рифкать Нургали улы | «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе» дәүләт бюджет фәнни учреждениесе президенты (килешү буенча) |
| Мөхәрләмов<br>Руслан Роберт улы | Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесе урынбасары – Татарстан Республикасы Рәисенең Эчке сәясәт мәсьәләләре департаменты җитәкчесе |
| Сабитова<br>Наталья Михайловна | «Татарстан Республикасының мордва милли-мәдәни мохтарияте» төбәк иҗтимагый оешмасы рәисе, «Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче халыклар вәкилләре ассамблеясе» төбәк иҗтимагый оешмасы рәисе урынбасары (килешү буенча) |
| Сәлимгәрәев<br>Айдар Сәетгәрәй улы | Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесе |
| Сәлахов<br>Рабис Мәгалим улы | «Россия рәссамнар берлеге» бөтенроссия иҗтимагый иҗади оешмасының төбәк бүлекчәсе «Татарстан Рәссамнар берлеге» рәисе (килешү буенча) |

| | |
|---|---|
| Самаренкин<br>Дмитрий Анатольевич | «Татарстан Республикасында чуваш милли-мәдәни мохтарияте» төбәк иҗтимагый оешмасы советы рәисе, «Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче халыклар вәкилләре ассамблеясе» төбәк иҗтимагый оешмасы рәисе урынбасары, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты (килешү буенча) |
| Сәүбәнова<br>Раушания Кыяметдин кызы | «Казан халык сәнгать һөнәрчелеге техникумы» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе директоры (килешү буенча) |
| Сафин<br>Ленар Ринат улы | «Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт автоном югары белем бирү мәгариф учреждениесе ректоры (килешү буенча) |
| Сөләйманов<br>Тимур Җәүдәт улы | Балаларның һәм яшьләрнең «Беренчеләр хәрәкәте» бөтенроссия иҗтимагый-дәүләт хәрәкәтенең Татарстан Республикасы төбәк бүлекчәсе советы рәисе (килешү буенча) |
| Сусаев<br>Сәлим Сәйф улы | Татарстан Республикасының «Вайнах» (Безнең халык) чечен милли-мәдәни берләшмәсе» төбәк иҗтимагый оешмасы рәисе, «Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче халыклар вәкилләре ассамблеясе» төбәк иҗтимагый оешмасы рәисе урынбасары (килешү буенча) |
| Һадиуллин<br>Илсур Гәрәй улы | Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министры |
| Хәсәнов<br>Гали Әхтәр улы | «Татарстан Республикасының башкорт милли-мәдәни мохтарияте – башкортлар корылтае (конгрессы)» төбәк иҗтимагый оешмасы рәисе (килешү буенча) |

| | |
|---|---|
| Ягъфәров<br>Илдар Рәшит улы | «Россия Федерациясе Кинематографиячеләр берлеге» гомумроссия җәмәгать оешмасының Татарстан Республикасы төбәк бүлекчәсе идарәсе рәисе (килешү буенча) |

---